ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

03.11.2017 Казан ш. № 3-3/э

Татарстан Республикасында халыкка һәм кулланучыларның аңа тиңләштерелгән категорияләренә 2018 елга электр энергиясе бәяләренә (тарифларына) киметүле коэффициентлар куллану хакында

«Электр энергетикасы турында» 2003 елның 26 мартындагы 35-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Электр энергетикасы өлкәсендә тарифларны дәүләти җайга салу турында» 2011 елның 29 декабрендәге 1178 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2018 елның 1 гыйнварыннан башлап 2018 елның 31 декабренә кадәр Татарстан Республикасында халык өчен электр энергиясе бәяләренә (тарифларына) карата киметүле 0,7 коэффициентының кулланылуын билгеләргә:

1.1. шәһәр торак пунктларында, азык әзерләү өчен билгеләнгән тәртиптә стационар электр плитәләре һәм (яки) электрдан җылытучы җайланмалар белән җиһазланган йортларда яшәүчеләр өчен;

1.2. авыл торак пунктларында яшәүчеләр өчен.

2. 2018 елның 1 гыйнварыннан башлап 2018 елның 31 декабренә кадәр Татарстан Республикасында кулланучыларның халыкка тиңләштерелгән аерым категорияләре өчен электр энергиясе бәяләренә (тарифларына) карата киметүле коэффициентларның шушы карар кушымтасына туры китереп кулланылуын билгеләргә.

3. 2018 елның 1 гыйнварыннан башлап 2018 елның 31 декабренә кадәр, шушы карарның 2 пунктында күрсәтелгән кулланучылардан тыш, Татарстан Республикасында халыкка тиңләштерелгән кулланучылар өчен электр энергиясе бәяләренә (тарифларына) карата киметүле коэффициентның кулланылмавын билгеләргә.

4. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис М.Р.Зарипов

Татарстан Республикасы
Тарифлар буенча дәүләт комитетының
03.11.2017 № 3-3/э карарына кушымта

## Татарстан Республикасында кулланучыларның халыкка тиңләштерелгән категорияләре өчен 2018 елга электр энергиясе бәяләренә (тарифларына) киметүле коэффициентлар

<table>
<tr><td rowspan="3">№ п/п</td><td rowspan="3">Кулланучыларның халыкка тиңләштерелгән категорияләре</td><td colspan="4">Киметүле коэффициентлар</td></tr>
<tr><td colspan="2">01.01.2018 башлап 30.06.2018 кадәр</td><td colspan="2">01.07.2018 башлап 31.12.2018 кадәр</td></tr>
<tr><td>шәһәр торак пунктларында урнашкан, азык әзерләү өчен билгеләнгән тәртиптә стационар электр плитәләре һәм (яки) электрдан җылытучы җайланмалар белән җиһазланган торакларда торучылар</td><td>авыл торак пунктларында торучылар</td><td>шәһәр торак пунктларында урнашкан, азык әзерләү өчен билгеләнгән тәртиптә стационар электр плитәләре һәм (яки) электрдан җылытучы җайланмалар белән җиһазланган торакларда торучылар</td><td>авыл торак пунктларында торучылар</td></tr>
<tr><td>1</td><td>Гражданнарның бакчачылык, яшелчәчелек яки дача буенча коммерциячел булмаган берләшмәләре – гражданнар тарафыннан ирекле башлангычларда бакчачылык, яшелчәчелек һәм дача хуҗалыгын алып баруда аның әгъзаларына уртак социаль-хуҗалык бурычларын хәл итүдә булышу өчен гамәлгә куелган, коммерциячел булмаган оешмалар.<br>Электр энергиясен (куәтен) алга таба халыкка һәм аңа тиңләштерелгән, кулланучыларның шушы <1> пунктта күрсәтелгән категорияләренә сату максатларында сатып алучы гарантияле рәвештә җиткерүчеләр, энергия сатучы, энрегия белән тәэмин итүче оешмалар.</td><td>0,7</td><td>0,7</td><td>0,7</td><td>0,7</td></tr>
<tr><td>2</td><td>Мәхәллә кешеләре хисабына яшәүче дини оешмалар.</td><td>-</td><td>0,7</td><td>-</td><td>0,7</td></tr>
</table>

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | Электр энергиясен (куәтен) алга таба халыкка һәм аңа тиңләштерелгән, кулланучыларның шушы <1> пунктта күрсәтелгән категорияләренә сату максатларында сатып алучы гарантияле рәвештә җиткерүчеләр, энергия сатучы, энрегия белән тәэмин итүче оешмалар. | | | | |

<1> – Электр энергиясен (куәтен) алга таба халыкка һәм кулланучыларның аңа тиңләштерелгән категорияләренә караган тиешле кулланучылар категорияләре булган очракта, халык һәм аңа тиңләштерелгән кулланучылар категорияләре тарафыннан фактта куллану күләмнәрендә һәм гражданнарның коммуналь-көнкүреш ихтыяҗларында файдалану максатларында уртак файдаланыла торган урыннарга тотылган һәм коммерциячел (һөнәри) эшчәнлек башкару өчен кулланылмый торган электр энергиясе күләмнәрендә сату максатларында сатып алучы гарантияле рәвештә җиткерүчеләр, энергия сатучы, энергия белән тәэмин итүче оешмалар.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге